**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Старосалмановского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Салман авыл җирлеге СОВЕТЫ**

Адрес: 422894, РТ, с. Старые Салманы, ул. Клубная, д.1
тел: 8 (84346) 79-8-49

Адресы: 422894, РТ, Иске Салман авылы, Клуб ур,1 йорт
факс: 8 (84346) 79-8-49

РЕШЕНИЕ Иске Салман авылы КАРАР

2021 елның 7 июне 20 №

Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге «Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге»муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү, шулай ук «Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 259-ФЗ номерлы Федераль закон, "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге»муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү, шулай ук «Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү турындагы нигезләмәне раслау хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктның «в» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) Мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш барганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты,

транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында».

13 пунктта «оешмалар)» сүзеннән соң « цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге
Советы Рәисе: А.Р.Халиуллин